**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясе турында» 2012 елның 18 июнендәге ПУ-477 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 30 ноябрендәге ПУ-920 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамасына «2028 елга кадәр» сүзләрен өстәргә;

б) 1 пунктка «2028 елга кадәр» сүзләрен өстәргә;

в) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясе» сүзләрен «2028 елга кадәр Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясе» сүзләренә алмаштырырга;

г) Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясен кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 05 июль
№ 474

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «05» июлендәге
474 номерлы Указына
кушымта

**2028 елга кадәр Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясе**

I. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш максатларының
гомуми тасвирламасы

1.1. 2028 елга кадәр Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясе (алга таба – Инвестиция декларациясе) түбәндәге максатларда эшләнде:

Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен уңай инвестиция климаты тәэмин итү;

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешен тәэмин итү һәм аның халкының тормыш дәрәҗәсен яхшырту;

эшкуарлык эшчәнлеген тотрыклы рәвештә алып бару һәм үстерү өчен шартлар булдыру.

1.2. Татарстан Республикасының инвестиция үсешенең төп максатлары түбәндәгеләр:

үсешнең илкүләм максатына ирешүгә өлеш кертү буларак төп капиталга инвестицияләрнең реаль үсешен тәэмин итү – 2020 ел күрсәткече белән чагыштырганда 2030 елга кадәр 70 процентка (Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары буенча 2020 елда – 615 593 млн сум);

Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеген алып баруның аңлаешлы һәм ачык шартларын билгеләү юлы белән инвестиция климатын яхшырту.

1.3. Инвестиция декларациясе эшкуарларга дәүләт ярдәме чараларының һәм эшкуарлык эшчәнлеге алып бару өчен шартларның тотрыклылыгы, актуальлеге, һәркемнең алардан файдалана алу мөмкинлеге булуы һәм нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат бирә.

1.4. Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә җайга салына.

1.5. Татарстан Республикасында төп капиталга инвестицияләр җәлеп итү һәм аларның күләмен арттыру мөмкинлеге бирә торган эшкуарлык эшчәнлегенә дәүләт ярдәме чаралары эшләнде һәм актив кулланыла, алар эш урыннары булдыруга, өстәмә бәяне һәм салым түләүләрен арттыруга ярдәм итә.

1.6. Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашырганда инвестиция процессында катнашучыларның тигез хокукларын тәэмин итү, конкуренцияне үстерүгә ярдәм күрсәтү, шулай ук эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның ташламалы режимнары булган инвестиция мәйданчыкларының, шул исәптән аларның гамәлдә булу вакыты дәвамында Татарстан Республикасының махсус икътисадый зоналарын һәм алгарышлы үсеш территорияләрен кертеп, эшләвен тәэмин итү гарантияләнә.

1.7. Инвестиция декларациясенең тексты, шулай ук аңа кушымта итеп бирелгән инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары исемлеге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Инвестиция порталында (www.invest.tatarstan.ru) урнаштырылган.

## II. Татарстан Республикасында яңа инвестиция проектларына ярдәм итү системасының гомуми тасвирламасы

2.1. Татарстан Республикасында яңа инвестиция проектларына ярдәм итү системасы (алга таба – Стандарт) Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2021 елның 30 сентябрендәге 591 номерлы «Россия Федерациясе субъектларында яңа инвестиция проектларына ярдәм итү системасы («Төбәк инвестиция стандарты») турында» боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасында кертелгән Стандарт элементлары түбәндәгеләр:

а) инвестиция декларациясе.

Инвестиция декларациясе Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясе турында» 2012 елның 18 июнендәге ПУ-477 номерлы Указы нигезендә расланды.

Инвестиция декларациясе Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыру шартлары буенча инвесторлар алдында йөкләмәләр, аларның начар якка үзгәрмәве һәм Татарстан Республикасы инвестиция командасында җаваплылыкны бүлү турында мәгълүматны бирә;

б) инвестиция комитеты.

Инвестиция комитеты сыйфатында Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестицион советын төзү турында» 2012 елның 5 июлендәге ПУ-538 номерлы Указы нигезендә расланган Татарстан Республикасы Инвестиция советы эшли. Татарстан Республикасы Инвестиция советының рәисе булып Татарстан Республикасы Рәисе тора.

Татарстан Республикасы Инвестиция советы инвестиция эшчәнлеген алып бару өчен уңайлы шартлар тудыру, инвестиция эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, инвесторның Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы (алга таба –

Агентлык) тарафыннан җайга салынмаган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, вәкаләтле оешмалар белән Татарстан Республикасы территориясендә инвестицион проектларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча булган каршылыкларын һәм бәхәсләрен судка кадәрге тәртиптә хәл итү өчен эшли;

в) үсеш агентлыгы.

Агентлык Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга хосусый инвестицияләрне җәлеп итүне, Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт-хосусый партнерлык механизмнарын кулланып, инвесторга Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тиз арада гамәлгә ашыруга ярдәм итүне, Татарстан Республикасының уңай инвестиция климатын формалаштыру һәм инвестицияләр җәлеп итү мөмкинлекләрен арттыруны тәэмин итүче Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы булып тора. Агентлык турында нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы мәсьәләләре» 2011 елның 6 июнендәге 460 номерлы боерыгы нигезендә расланды.

Агентлык Татарстан Республикасы Инвестиция советы эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати-аналитик яктан тәэмин итүне, инвестиция проектын алып баруга электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге булган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Инвестиция порталын (www.invest.tatarstan.ru) алып баруны тормышка ашыра.

г) инвестиция картасы.

Татарстан Республикасы инвестиция картасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Инвестиция порталында (www.invest.tatarstan.ru/ru/map) урнаштырылган.

Татарстан Республикасы инвестиция картасы инвесторларга Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен ресурсларны, кирәкле инфраструктураны, мәйданчыкларны бүлү, преференциаль режимнарның (алгарышлы үсеш территорияләре, махсус икътисадый зоналар) булуы турында Татарстан Республикасы турында мәгълүматтан файдала алуы тәэмин итә;

д) инвестиция кагыйдәләре җыелмасы.

Татарстан Республикасы инвестиция кагыйдәләре җыелмасына инвесторның инвестиция проектын әзерләгәндә һәм гамәлгә ашырганда күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту өчен эшләнгән гамәлләр алгоритмнары керә:

файдалануга тапшырылган объектка милек хокукларын рәсмиләштерү буенча;

сәүдә уздырып, җир кишәрлеген арендага алу буенча;

сәүдә уздырмыйча, җир кишәрлеген арендага алу буенча;

электр челтәрләренә тоташтыру буенча;

су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу объектларына тоташтыру буенча;

төзелешкә рөхсәт алу буенча;

объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт алу буенча;

җылылык белән тәэмин итү челтәрләренә технологик тоташтыру буенча;

газ җиһазларын һәм капиталь төзелеш объектларын газ бүлү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) буенча;

автомобиль юллары кисешкән һәм (яки) тоташкан урыннарны төзү яисә реконструкцияләү юлы белән юл инфраструктурасыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча.

Стандарт элементлары турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Инвестиция порталының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Инвестиция стандарты» бүлегендә (https://invest.tatarstan.ru/ru/investment-standard/) урнаштырылган.

## III. Татарстан Республикасының төп характеристикалары

3.1. Татарстан Республикасы – Россия Федерациясенең сәнәгать, фәнни, авыл хуҗалыгы, инновация тармакларында потенциалы булган социаль-икътисадый яктан әйдәп баручы субъекты.

Татарстан Республикасының мәйданы 67 837,4 кв. километр тәшкил итә, республика составына 43 муниципаль район һәм ике шәһәр округы керә.

3.2. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешен фаразлауның төп күрсәткечләре Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (mert.tatarstan.ru/SEPrognoz/SER_RT.html) урнаштырылган.

Татарстан Республикасы төп макроикътисадый күрсәткечләр буенча Россия Федерациясе субъектлары арасында лидерлык позицияләрен саклый:

төзелеш – 4 нче урын (2022 ел йомгаклары буенча);

сәнәгать җитештерүе һәм авыл хуҗалыгы – 5 нче урын (2022 ел йомгаклары буенча);

төп капиталга инвестицияләр – 6 нчы урын (2022 ел йомгаклары буенча);

тулаем төбәк продукты – 6 нчы урын (2021 ел йомгаклары буенча);

ваклап сату әйләнеше – 7 нче урын (2022 ел йомгаклары буенча).

2022 ел нәтиҗәләре буенча тулаем төбәк продукты күләме бәяләү буенча 3 865,1 млрд сум, ягъни 2021 елга карата чагыштырма бәяләрдә 106,0 процент тәшкил итте.

Икътисад структурасында чагыштырмача иң зур урынны бәяләү буенча гадәттәгечә, сәнәгать алып тора – 49,2 процент, авыл хуҗалыгы – 4,9 процент, төзелеш – 7,1 процент, кумәртәләп һәм ваклап сату – 9,4 процент, транспортлау һәм саклау – 5,2 процент тәшкил итте.

2021 елда сәнәгать оешмаларының үзләре җитештергән товарлары, эшләре, күрсәтелгән хезмәтләрнең гомуми күләмендә инновация продукциясе өлеше 20,8 процент тәшкил итте.

Татарстан Республикасы сәнәгатендә 115 меңгә якын предприятие эшли, шуларның иң зурлары – В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте, «Сибур-РТ» акционер җәмгыяте, «ТАИФ-НК» акционер җәмгыяте, «Татэнерго» акционер җәмгыяте, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте, «Соллерс Алабуга» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «АУРУС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «ХАЙЕР ИНДАСТРИ РУС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Ак Барс» холдинг компаниясе» акционер җәмгыяте, «Туполев» гавами акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы, «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыяте, «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте.

Татарстан Республикасында мәгълүмат технологияләре, туристлык, мәгариф, мәдәният, спорт өлкәсе үсеш алган.

3.3. Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары буенча 2022 елга икътисадта уртача эшче көч саны 1 986,6 мең кеше (эшче көченең 97,7 проценты) мәшгуль һәм 46,3 мең кеше (2,3 процент) эшләми, әмма актив рәвештә аны эзли. Иң күп эшләүчеләр саны эшкәртү производствосында (250,2 мең кеше), мәгарифтә (145,1 мең кеше), сәүдәдә (137,3 мең кеше), транспортлау һәм саклауда (110,2 мең кеше), сәламәтлек саклауда (97,3 мең кеше) хезмәт куя.

2021 елда югары белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларның гомуми саны якынча 2022 елда 28 944 кеше тәшкил итте. Татарстан Республикасында 45 югары белем бирү мәгариф оешмасы бар, шулардан иң зурлары – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе, «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе, «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе.

Һөнәри белем бирү оешмаларын елына якынча 17,5 мең укучы тәмамлый. Татарстан Республикасы территориясендә 99 һөнәри белем бирү оешмасы эшли, алар базасында предприятиеләр белән берлектә 45 ресурс үзәге булдырылды. Кадрлар әзерләү өчен инвестор Татарстан Республикасының халыкара стандартлар нигезендә өр-яңа җиһазлары, кадрлар потенциалы һәм белем бирү программалары булган Татарстан Республикасы ресурс үзәкләреннән файдалана яисә яңасын булдыра ала. Ресурс үзәкләре һөнәри программаларның эчтәлеген тиз арада яңартуны, предприятиенең үзенчәлегенә карап, кадрлар әзерләячәк яңа база булдыру мөмкинлеген тәэмин итә.

3.4. Татарстан Республикасында төбәкнең инвестицион мөмкинлекләрен алга таба танытуга һәм аның инвестицион климатын яхшыртуга, шулай ук инвесторларга бизнес алып бару өчен уңайлы шартлар булдыруга зур игътибар бирелә. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы эшчәнлеге йомгаклары турындагы хисап мәгълүматлары буенча, 2022 елда төп капиталга инвестицияләр күләме 888,6 млрд сум тәшкил иткән, ягъни 2021 ел белән

чагыштырганда 110,5 процент. 2022 елның гыйнвар – декабрь айларында кече эшкуарлык субъектлары булып тормаган оешмалар буенча төп капиталга инвестицияләр зур күләмдә эшкәртү производстволарын үстерүгә юнәлтелгән – төп капиталга инвестицияләрнең гомуми күләменең 25,1 проценты (шул исәптән 9,2 проценты – нефть продуктлары җитештерүгә, 6 проценты – химик матдәләр һәм химик продуктлар җитештерүгә, 2,6 проценты – автотранспорт чаралары, прицеплар һәм ярымприцеплар җитештерүгә), транспортлау һәм саклауга – 24,2 проценты, файдалы казылмалар чыгаруга – 12,1 проценты, күчемсез милек белән операцияләр эшчәнлегенә – 8,3 проценты, авыл, урман хуҗалыгы, аучылык һәм балыкчылык һәм балык үрчетүгә – 4,7 проценты.

3.5. Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен барлык кирәкле шартлар бар.

Россия Федерациясе законнары, шул исәптән «Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законны, «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясендә алгарышлы үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм хуплау турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законны, шулай ук «ВЭБ.РФ» үсеш дәүләт корпорациясен, «Россиянең технологик үсеш фонды» федераль дәүләт автоном учреждениесен, «Фәнни-техник өлкәдәге предприятиеләрнең кече формаларны үстерүгә булышлык итү фонды» федераль дәүләт бюджет учреждениесен һәм башкаларны кертеп, федераль үсеш институтлары программалары нигезендә федераль ярдәм чаралары күрсәтелә;

Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Җир кодексын, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Оешмалар мөлкәтенә салым салу турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2008 елның 2 августындагы 53-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда салым салуның аерым мәсьәләләрен җайга салу турында» 2022 елның 21 мартындагы 11-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе

турында нигезләмәне раслау турында» 1999 елның 7 маендагы 284 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының өч еллык чорга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында карарлары, шулай ук «Татарстан Республикасының эшкуарлыкка ярдәм итү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясен, «Татарстан Республикасы гарантия фонды» коммерциячел булмаган оешмасын, «Татарстан Республикасы инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасын һәм башкаларны кертеп, республика үсеш институтлары программалары нигезендә төбәк ярдәм чаралары күрсәтелә;

Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә, шул исәптән арендаторларны җир өчен салым түләүдән, аренда түләүләреннән азат итү яки ташламалы шартларда аренда түләүләре алу мөмкинлеге бирүне, мөлкәтне бушлай, сайланган эшчәнлек төрләре буенча аукционнар үткәрмичә алу, билгеле бер төр хезмәтләр күрсәткәндә чыгымнарның бер өлешен каплау, җирле үзидарә органнарының хокукый актлары нигезендә кредит буенча ташламалы ставканың бер өлешен субсидияләүне кертеп, муниципаль ярдәм чаралары күрсәтелә.

Татарстан Республикасының Инвестиция порталындагы (invest.tatarstan.ru) «Ярдәм чаралары» бүлегендәге, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, махсус икътисадый зоналар, индустриаль (сәнәгать) паркларның алгарышлы үсеш территорияләре һәм башка инвестиция инфраструктура объектларының сайтларында урнаштырылган мәгълүмат ярдәмендә, шулай ук инвестиция юнәлештәге гавами чаралар аша ярдәм чаралары турында җыелма мәгълүмат белән һәркем таныша ала.

3.6. Татарстан Республикасында социаль объектлар төзелешендә дәүләт-хосусый һәм муниципаль-хосусый партнерлык механизмнары киң кулланыла. 2022 елда дәүләт-хосусый партнерлыгын үстерү дәрәҗәсе буенча Россия Федерациясе субъектлары рейтингында Татарстан Республикасы дәүләт-хосусый партнерлыкны үстерү дәрәҗәсе буенча Россия төбәкләре арасында 4 нче урында тора. Әлеге механизмнар «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә дәүләт-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кулланыла.

2022 елга Татарстан Республикасында 150 дән артык концессия килешүе төзелде, шулардан иң зурысы – Шәле (М-7) – Баулы (М-5) түләүле автомобиль юлы составындагы Алексеевск-Әлмәт (трасса «АА») автомобиль юлын төзү һәм эксплуатацияләү турында концессия килешүе, әлеге проектны гамәлгә ашыруга инвестицияләрнең күләме 82,5 млрд сум тәшкил итә. «АА» трассасы бер үк вакытта Европа – Көнбатыш Кытай транспорт коридорының бер этабы булачак.

Концессия килешүләре Татарстан Республикасында 2011 елдан бирле гамәлгә ашырыла, биредә «Россия Федерациясендә дәүләт-хосусый

партнерлыгы, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә объектның инвестор милкенә күчүен күздә тоткан Россиядә беренче инвестиция проекты гамәлгә ашырылды. Чаллы шәһәрендә «Клевер» спорт-сәламәтләндерү комплексын төзү шундый проект булып тора.

3.7. Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә салым ташламалары рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтелә башлаганнан бирле (2006 елдан) гомуми суммасы 16 млрд сумга якын ташламалар бирелде, Татарстан Республикасы бюджетына салым түләүләре якынча 27,2 млрд сум тәшкил итте. Әлеге инвестиция проектларын гамәлгә ашыру кысаларында 761 млрд сум күләмендә инвестицияләр җәлеп ителде, 18 меңнән артык яңа эш урыны булдырылды.

3.8. Татарстан Республикасы территориясендә ике махсус икътисадый зона (алга таба – МИЗ): сәнәгать-җитештерү тибындагы «Алабуга» МИЗ һәм техник-гамәлгә кертү тибындагы «Иннополис» МИЗ уңышлы эшләп килә, аларның эшчәнлеге «Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына. Резидентлар өчен махсус икътисадый зоналарның төп өстенлекләре: федераль һәм төбәк дәрәҗәсендә салым ташламалары, инвестиция шартларының тотрыклылыгын гарантияләү, әзер инфраструктура, ташламалы аренда һәм җир кишәрлекләрен сатып алу, сәнәгать-җитештерү тибындагы «Алабуга» МИЗда түләүләрсез таможня зонасы (җиһазлар, чимал һәм материалларны пошлинасыз кертү).

2005 елдан Татарстан Республикасында «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона эшләп килә, ул Россия махсус икътисадый зоналарының (Россия кластерлары, технопарклары һәм МИЗ ассоциациясе) инвестицияләр җәлеп итүчәнлеге илкүләм рейтингын төзү чоры дәвамында тотрыклы рәвештә лидерлык позицияләрен биләп тора. Әлеге махсус икътисадый зона инфраструктура белән тәэмин ителеше, резидентларның инвестицияләр күләменең МИЗ территориясендә арендага яраклы мәйданга нисбәте буенча абсолют лидер булып тора. Моннан тыш, «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы МИЗ идарәче компаниянең чит ил инвесторларын җәлеп итү өчен компетенцияләре булу буенча башка махсус икътисадый зоналар арасында лидер булып тора, МИЗ сәнәгать революциясе технологияләре 4.0 белән тәэмин ителеше буенча иң яхшы күрсәткечләргә ия. Хәзерге вакытта «Алабуга» МИЗ идарәче компаниясе 2 мең гектар мәйданда «Этилен 600» индустриаль паркын төзи. Әлеге карар медицина, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм башка тармакларда товар җитештерүчеләр өчен уникаль мөмкинлекләр тәрәзәсен булдырырга мөмкинлек бирәчәк, алар өчен чимал булып Түбән Камадагы «СИБУР» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте предприятиеләренең нефть-газ химиясе продукциясе була ала.

2012 елдан Татарстан Республикасында «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зона эшли, ул 2022 ел йомгаклары

нигезендә «Россия махсус икътисадый зоналары буенча бизнес-навигатор» басмасы версиясе буенча инвестицияләр җәлеп итүчәнлеге югары дәрәҗәдә булган әйдәп баручы махсус икътисадый зоналар төркеменә керә. Моннан тыш, «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасында Россия өчен уникаль булган ИТ-белгечләр өчен экосистемалы IT-шәһәр бар.

Татарстан Республикасы территориясендәге ике МИЗ да проектларны уртак финанслау, инфраструктура һәм резидентлар өчен биналар төзү, әлеге юнәлештә эшләү өчен кадрлар сайлау һәм әзерләү белән шөгыльләнүче югары профессиональ идарәче компанияләр эшли. «Алабуга Политех» – укучылар саны буенча Россиядә эшче белгечлекләр әзерләү өлкәсендә иң зур белем бирү үзәге, «Иннополис» Университеты» автоном коммерциячел булмаган югары белем бирү оешмасы Россиядәге бердәнбер ИТ-университет.

3.9. Татарстан Республикасында Чаллы, Түбән Кама, Менделеевск, Зеленодольск, Чистай моношәһәрләрендә урнашкан 5 алгарышлы үсеш территориясе бар. 2023 елның 30 гыйнварына Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы реестры мәгълүматлары буенча Татарстан Республикасы алгарышлы үсеш территорияләре һәм әлеге территорияләрдәге резидентлар саны буенча беренче урында.

3.10 Россия индустриаль парклары ассоциациясенең 2022 елга «Россия индустриаль парклары» тармак күзәтүе мәгълүматлары буенча Татарстан Республикасы сәнәгать парклары Россия сәнәгать паркларына кертелгән барлык инвестицияләрнең 16,3 процентын үз эченә ала. Татарстан Россиядә сәнәгать парклары саны буенча беренче урын алып тора – алар 100дән артык, шуларның 70 тән артыгында – ташламалы аренда алуга мөмкинлеге бар һәм алар тиешле аккредитация узган.

Татарстан Республикасында «Хайер Рус», «Пионер» сәнәгать парклары эшли, әлеге паркларда идарәче компанияләр булып чит ил предприятиеләре тора.

3.11. «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте ел әйләнәсендә тимер юл һәм елына 6 ай дәвамында су транспортында продукция ташу мөмкинлеге бирә. Татарстанның Идел елгасы буенча транспорт юлында уңайлы урнашуы Азиядән йөк ташу өчен уникаль мөмкинлекләр бирә.

3.12. Татарстан Республикасында зур инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга ярдәм итүнең тагын бер коралы булып инвестор һәм гавами-хокукый берәмлек арасында «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм хуплау турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелә торган капитал салуларны яклау һәм хуплау турында килешү тора, аның нигезендә гавами-хокукый берәмлек инвесторга мөнәсәбәтле рәвештә аның хәлен начарлатуга китерүче (тотрыклыландыру төзәтмәсе) яки проектны гамәлгә ашырганда өстәмә каршылыклар яки чыгымнар тудыручы хакимият органнары актларының (карарларының) кулланылмавын тәэмин итәргә бурычлы.

Тотрыклыландыру төзәтмәсе 3 елдан 20 елга кадәр кулланырга мөмкин. Компенсациянең чик күләме инвестиция проектын гамәлгә ашыру белән бәйле түләнгән мәҗбүри түләүләр нигезендә белән билгеләнә һәм тәэмин итүче инфраструктураны булдырганда һәм инвестиция фазасында процентлар (купон кереме) түләгәндә чыгымнарның 50 процентыннан; өстәмә инфраструктура төзегәндә чыгымнарның 100 процентыннан артмаска тиеш. Килешү төзү өчен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган проектларга инвестицияләрнең минималь чик күләме 200 млн сум тәшкил итә.

3.13. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, башка Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары үз вәкаләтләре кысаларында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвестиция эшчәнлеген алып бару өчен кирәкле рөхсәт документларын килештерү һәм бирү срокларының үтәлешен тәэмин итә.

3.14. Татарстан Республикасында үстерелә торган өстенлекле тармаклар түбәндәгеләр:

химия һәм нефть химиясе сәнәгате;

машина төзелеше һәм металл эшкәртү;

мәгълүмат технологияләре һәм телекоммуникацияләр;

агросәнәгать комплексы;

төзелеш;

медицина һәм фармацевтика;

хезмәт күрсәтү һәм туризм;

фәнни үсеш.

3.15. Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан фән, технологияләр һәм техника үсешенең өстенлекле юнәлешләре, шулай ук критик технологияләр исемлеге раслана.

## IV. Татарстан Республикасының инвестиция йөкләмәләре

4.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз вәкаләтләре чикләрендә һәм Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә барлык инвестиция эшчәнлеге субъектларына, аларның милек рәвешенә карамастан, түбәндәге гарантияләр бирә ала торган норматив хокукый актлар кабул итә:

а) инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашырганда тигез хокуклылыкны тәэмин итү, инвестиция проектлары турында фикер алышуда хәбәрдарлык;

б) «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм хуплау турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль Закон нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру шартларының начарланмавы, аларны гамәлгә ашыруның бөтен срогы дәвамында капитал салуларны яклау;

в) инвесторның инвестиция кагыйдәләре җыелмасы кысаларында инфраструктурага кушылу гамәлләре алгоритмнарын үтәү,

г) Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларында яңа инвестиция проектларына ярдәм итү системасы («Төбәк инвестиция стандарты») турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 591 номерлы боерыгы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестицион советын төзү турында» 2012 елның 5 июлендәге ПУ-538 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган бәхәсләрне судка кадәрге тәртиптә оператив карап тикшерү;

д) Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүне оптимальләштерү буенча Россия Икътисадый үсеш министрлыгының эшен оештыру турында» 2021 елның 2 сентябрендәге 520 номерлы боерыгы нигезендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә процедураларның срокларын һәм санын киметү;

е) Россия Федерациясе законнары нигезендә инвестиция эшчәнлеге алып бару өчен кирәкле рөхсәт документларын килештерү һәм бирү срокларын үтәү һәм киметү;

ж) Татарстан Республикасы территориясендә «Дәүләт сере турында» 1993 елның 21 июлендәге 5485-I номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә дәүләт һәм федераль закон нигезендә саклана торган башка серне тәшкил иткән мәгълүматтан кала, инвестиция эшчәнлегенә дәүләт ярдәме чаралары турында мәгълүмат белән һәркемнең таныша алу мөмкинлеге;

з) «Россия Федерациясе субъектларында конкурентлыкны үстерү стандартын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 апрелендәге 786-р номерлы боерыгы һәм Татарстан Республикасы Рәисе Боерыгы нигезендә 3 елга раслана торган Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планына (юл картасы) таянып, Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатлары өчен ресурсларны конкурентлы бүлүне тәэмин итү;

и) Татарстан Республикасы халкының керемнәр дәрәҗәсен арттыру.

## V. Татарстан Республикасының инвестиция командасы

5.1. Татарстан Республикасының инвестиция командасы функцияләрен, бурычларын һәм аңа йөкләнгән җаваплылыкны бүлү:

а) Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасының эчке сәясәтен һәм тышкы эшчәнлек юнәлешләрен Татарстан Республикасы Рәисе билгели;

б) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Премьер-министры оештыра;

в) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 23 июлендәге 325 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлегенә идарә итү буенча дәүләт сәясәтен эшләү һәм Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салу функцияләрен Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры гамәлгә ашыра;

г) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының «бер тәрәзә» принцибы нигезендә үзара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2019 елның 20 февралендәге 118 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә «бер тәрәзә» режимында инвесторларны җәлеп итү һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне Агентлык җитәкчесе гамәлгә ашыра;

д) «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе гамәлгә ашыра;

е) стандарт кертүгә эксперт бәяләмәсе бирүнең нәтиҗәле системасын булдыру һәм эшләү, инвестиция эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итү, эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары белән хезмәттәшлеген оештыру, уңай эшлекле климат формалаштыруны түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

«Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы турында» 2017 елның 13 ноябрендәге 81-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге рәисе (килешү буенча);

устав нигезендә Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) генераль директоры (килешү буенча);

устав нигезендә «ОПОРА РОССИИ» гомумроссия кече һәм урта эшкуарлык иҗтимагый оешмасының беренче вице-президенты, «ОПОРА РОССИИ» гомумроссия кече һәм урта эшкуарлык иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе Попечительләр советы рәисе (килешү буенча);

устав нигезендә «Эшлекле Россия» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлеге рәисе (килешү буенча);

ж) инвестиция һәм финанс эшчәнлеген гамәлгә ашыру, инвестиция капиталын җәлеп итү һәм эшкуарларга ярдәм күрсәтүне түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

устав нигезендә «Татнефтехиминвест-холдинг» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча);

устав нигезендә «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча);

устав нигезендә «Татарстан Республикасы эшкуарлыкка ярдәм итү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе генераль директоры (килешү буенча);

з) махсус икътисадый зоналар үсеше өчен түбәндәгеләр җаваплы:

устав нигезендә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча);

устав нигезендә «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча).

5.2. Инвестиция декларациясе максатларына ирешү мәсьәләләре, шул исәптән Татарстан Республикасы инвестиция командасы эшен оештыру белән бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Инвестиция советы утырышларында карап тикшерелә.

5.3. Татарстан Республикасының инвестиция командасын формалаштыру шартлары:

Татарстан Республикасының инвестиция командасын формалаштыру анда катнашучыларның компетенцияләре, проектлар белән эшләү тәҗрибәсе, белем дәрәҗәсе һәм квалификациясен исәпкә алып, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Инвестиция проектлары белән эшләү буенча белгеч» һөнәри стандартын раслау турында» 2018 елның 16 апрелендәге 239н номерлы боерыгы нигезендә башкарыла.

2028 елга кадәр
Татарстан Республикасы
Инвестиция декларациясенә
кушымта

**Инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары исемлеге**

1. Россия Федерациясе Бюджет кодексы.
2. Россия Федерациясе Салым кодексы.
3. Россия Федерациясе Җир кодексы.
4. «Россия Федерациясендә капитал кертүләр рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеге турында» 1999 елның 25 февралендәге 39-ФЗ номерлы Федераль закон.
5. «Россия Федерациясендә чит ил инвестицияләре турында» 1999 елның 9 июлендәге 160-ФЗ номерлы Федераль закон.
6. «Инвестиция фондлары турында» 2001 елның 29 ноябрендәге 156-ФЗ номерлы Федераль закон.
7. «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон.
8. «Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон.
9. «Ил оборонасын һәм дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен стратегик әһәмияткә ия хуҗалык җәмгыятьләренә чит ил инвестицияләрен кертүне гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2008 елның 29 апрелендәге 57-ФЗ номерлы Федераль закон.
10. «Инвестиция ширкәте турында» 2011 елның 28 ноябрендәге 335-ФЗ номерлы Федераль закон.
11. «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон.
12. «Россия Федерациясендә алгарышлы үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон.
13. «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон.
14. «Россия Федерациясендә дәүләт-хосусый партнерлыгы, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон.
15. «Инвестиция платформаларыннан файдаланып инвестицияләр җәлеп итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 августындагы 259-ФЗ номерлы Федераль закон.

16. «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм хуплау турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон.

17. Татарстан Республикасы Җир кодексы.

18. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы.

19. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

20. «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2008 елның 2 августындагы 53-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

21. «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

22. «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

23. «Татарстан Республикасында дәүләт-хосусый партнерлыгы турында» 2011 елның 1 августындагы 50- ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

24. «Татарстан Республикасында инвестиция салым кредиты турында» 2011 елның 10 октябрендәге 68-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

25. «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үсеше стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

26. «Татарстан Республикасы монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә булдырылган алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2016 елның 13 февралендәге 5-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

27. «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

28. «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда салым салуның аерым мәсьәләләрен җайга салу турында» 2022 елның 21 мартындагы 11-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

29. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының 2028 елга кадәр Инвестиция декларациясе турында» 2012 елның 18 июнендәге ПУ-477 номерлы Указы.

30. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестицион советын төзү турында» 2012 елның 5 июлендәге ПУ-538 номерлы Указы.

31. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 елның 9 февралендәге 74 номерлы карары.

32. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 елның 7 маендагы 284 номерлы карары.

33. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы мәсьәләләре» 2011 елның 6 июнендәге 460 номерлы карары.

34. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы инновация инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2013 елның 4 июнендәге 384 номерлы карары.

35. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумының өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 25 ноябрендәге 925 номерлы карары.

36. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 елның 27 августындагы 616 карары.

37. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәр) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлекне алып бару турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 елның 4 февралендәге 61 номерлы карары.

38. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт-хосусый партнерлык проектларына инвестицияләр җәлеп итүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эш төркеме төзү турында» 2016 елның 12 маендагы 300 номерлы карары.

39. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы мәсьәләләре» 2011 елның 6 июнендәге 460 номерлы карары нигезендә расланган Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт-хосусый партнерлык турында килешүләр реестрын формалаштыру һәм алып бару турында» 2012 елның 28 мартындагы карары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2016 елның 27 октябрендәге 789 номерлы карары.

40. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Концессия килешүе объекты бинасында Татарстан Республикасы халкына медицина хезмәтләрен күрсәтүне күздә тота торган Татарстан Республикасы белән концессия килешүе төзегән юридик затларга чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»

2017 елның 3 июлендәге 458 номерлы карары.

41. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Концессия килешүе объекты биналарында дәүләт медицина оешмаларында дәвалау туклануы хезмәтләрен күрсәтүне күздә тоткан Татарстан Республикасы белән концессия килешүе төзегән юридик затларга чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 10 августындагы 654 номерлы карары.

42. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бер тәрәзә» принцибы буенча Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2019 елның 20 февралендәге 118 номерлы карары.

43. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2019 елның 22 октябрендәге 949 номерлы карары.

44. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гавами проект инициативасын формалаштырганда капитал салуларны яклау һәм хуплау турында килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында декларация формасын раслау турында» 2021 елның 2 апрелендәге 211 номерлы карары.

45. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа инвестиция проектлары җыелма исемлегенә кертелгән яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында килешүләр, яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру буенча ниятләр турындагы килешүләргә кул куюга вәкаләтләр бирү, шулай ук яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру буенча ниятләр турындагы килешүләрнең үрнәк формасын раслау турында» 2021 елның 18 сентябрендәге 878 номерлы карары.

46. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт яисә муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектлар урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен юридик затларга сатуга куймыйча арендага бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 9 июнендәге 554 номерлы карары.

47. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 3 ноябрендәге 1041 номерлы карары.

48. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм хуплау турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясында билгеләнгән

үзенчәлекләрне исәпкә алып кулланыла торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары исемлеген раслау турында» 2022 елның 12 гыйнварындагы 7 номерлы карары.

49. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа инвестиция проектларын сайлап алу, бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасының Россия Федерациясе алдындагы бурычларын бетерү һәм яңа инвестиция проектларын сайлап алу буенча эш төркеме составы һәм бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасының Россия Федерациясе алдындагы бурычларын бетерү буенча эшне оештыру тәртибен раслау турында» 2022 елның 14 гыйнварындагы 14 номерлы карары.

50. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023–2025 елларга Татарстан Республикасының инвестиция меморандумын раслау турында» 2022 елның 7 декабрендәге 1296 номерлы карары.

51. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023–2025 елларга Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган 2023 елга өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2022 елның 30 декабрендәге 1464 номерлы карары.

___________